**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Совет Новоибрайкинского сельского поселения Аксубаевского муниципального района**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Аксубай муниципаль районы Яна Ибрай авыл җирлеге Советы**

**423079, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Новое Ибрайкино, ул. Советская, 5.**
Тел. (8-84344-4-27-27)

---

# КАРАР

**№ 11** **29.01. 2026 ел**

**Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советы "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 19.10.2015 № 5 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 N 425-ФЗ Федераль законы, Аксубай муниципаль районы «Яңа Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советы КАРАРы:

1. Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советы "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 19.10.2015 елгы 5 номерлы карарына ( 02.08.2018 елгы 64 номерлы, 26.11.2018 елгы 77а номерлы, 26.11.2018 елгы 76 номерлы, 14.12.2019 елгы 104, 13.11.2023 ел, № 64, 13.11.2024 ел 83 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 пунктчасындагы 5 абзацында "проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган тәмамланмаган төзелеш объектларыннан тыш" сүзләрен өстәргә;.

2. Әлеге карар 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Яңа Ибрай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Аксубай муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Ибрай авыл җирлеге

Башлыгы: Кәбиров Ф.Х..

СОВЕТ НОВОИБРАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ